# КАМЫШЛИНСКИЕ ИЗВЕСТИЯ

ПЯТНИЦА
19 МАЯ 2023 ГОДА
№ 35 (10103)

12+

Газета муниципального района Камышлинский · Основана в 1931 году

СОБЫТИЯ МИНУВШИХ ДНЕЙ



## Связь поколений

Илюся Гайнуллина.

**На фото - воспитанники старшей группы детского сада «Улыбка» совместно с воспитателями Венерой Гарифуллиной, Натальей Кандратьевой и учителем логопедом Гузялией Шайдуллиной выступили перед ветеранами с праздничным концертом в преддверии очередной годовщины Победы в Великой Отечественной войне.**

Мальчишки и девчонки пели, танцевали, рассказали стихи о войне, исполнили инсценировки, порадовали гостей теплыми словами, поздравлениями, благодарностями за мирное небо, счастливое детство. Старшее поколение было растрогано до слез и наградило юных артистов громкими аплодисментами.

Праздничное мероприятие, организованное для ветеранов, тружеников тыла, детей войны и труда районным Советом ветеранов войны и труда и обществом инвалидов при поддержке социальной службы, прошло в уютном зале комплексного центра социального обслуживания населения Северо-Восточного округа отделение муниципального района Камышлинский. Гостей поздравили с праздником руководитель отделения Наиля Габидуллина, от Совета ветеранов - Фагим Сафиуллин и Фагим Нуруллин. Они выразили слова благодарности и пожелали ветеранам здоровья и благополучия.


На празднике со своей концертной программой также выступил самодеятельный фольклорный коллектив «Дуслык», созданный в Камышле совсем недавно по инициативе творческого человека Айсылу Камалтдиновой. Были песни в исполнении Гульюзим Фазлиахметовой и Айсылу Камалтдиновой под аккомпанемент Бориса Камалтдинова. Артисты подарили приятные радостные мгновения всем присутствующим в зале, которые поддержали коллектив позитивным настроением. Любовь к татарской песне, музыке и пляске объединила в творческий коллектив «Дуслык» 15 интересных, увлечённых людей разных возрастов, профессий, каждый из которых является музыкантом, вокалистом, танцором. Дебютную музыкальную программу, интересную и разнохарактерную, собирается представить новый коллектив на сценах культурных учреждений района и за его пределами.

Организаторы приготовили для всех участников встречи праздничный стол, за чашкой чая ветераны вспомнили свои молодые годы, которые они посвятили за наше счастливое будущее. Остались в прошлом славный пройденный путь, с честью заслуженные трудовые награды, но жива в сердце память о тяжелых трудовых буднях в сердце каждого ветерана. И внимание, которое уделяется ветеранам в эти праздничные дни, для них очень дорого.

«Такие встречи поколений помогают сохранять память о подвигах наших дедов и отцов, лучше узнать историю своей страны. И зрители, и артисты получили сегодня массу положительных впечатлений», - делится с нами председатель районного общества инвалидов Зульфия Дерзиманова.

С хорошим настроением и приятными впечатлениями расходились по домам ветераны.

**Продолжается подписка на газету "Камышлинские известия"**



стоимость подписки на полугодие:
С ДОСТАВКОЙ - 553,68 руб.;
ЛЬГОТНАЯ (ветераны ВОВ, инвалиды) - 475,98 руб.;
БЕЗ ДОСТАВКИ (в редакции) - 150 руб.

ПРИЯТНЫЕ ИЗМЕНЕНИЯ




# НОВЫЕ ДОРОГИ – НА РАДОСТЬ ЖИТЕЛЯМ

### В СЕЛЕ КАМЫШЛА ЗААСФАЛЬТИРУЮТ УЧАСТКИ ДОРОГ ПО УЛИЦАМ РЕВОЛЮЦИИ И КОММУНАЛЬНАЯ

Ирина Макарова.

**Работы по ремонту дорог в селе Камышла стартовали по государственной программе «Развитие транспортной системы Самарской области на 2014-2025 годы». Это поможет улучшить транспортную инфраструктуру, что соответствует задачам национального проекта «Безопасные качественные дороги».**

Повышения качества транспортной инфраструктуры на объектах местного значения и создание комфортных условий для жителей - задачи, которые ставит и держит на контроле губернатор Самарской области Дмитрий Азаров.

Программой запланировано асфальтирование участков дорог по улицам Революции и Коммунальная. По улице Революции будут заасфальтированы два участка: от дома №2 до дома №28 и от дома №21 до дома №51. По улице Коммунальная будет заасфальтирован участок от дома №1 до дома №19.

При выборе объектов для асфальтирования учитывали приближенность дорог к социально важным учреждениям. Во время проведения массовых мероприятий сотрудники полиции перекрывают центр села Камышла для безопасности жителей. В это время автомобилисты вынуждены объезжать центр по соседним улицам, дороги которых часто покрыты ямами и ухабами.

На сегодняшний день подрядчик начал снимать грунт под дорожную подушку по улице Революции райцентра Камышла.

«Благодаря субсидии, предоставленной Министерством транспорта и автомобильных дорог Самарской области на осуществление дорожной деятельности в отношении автомобильных дорог общего пользования местного значения, в том числе в рамках реализации нацпроекта «Безопасные качественные дороги», увеличится количество асфальтированных сельских дорог. Такая поддержка помогает решать проблемные вопросы и делать жизнь в селе комфортнее», - отмечает глава муниципального района Камышлинский Рафаэль Багаутдинов.

Ремонт дороги - событие большое для жителей данных улиц. «Это долгожданное событие для нас, - поделился своим мнением Руслан Галиуллин, житель улицы Революции. - Об этом можно было только мечтать. Вместо булыжников и грязи будет асфальт. Мы расцениваем это, как внимание власти к развитию сельской территории».

СВОИХ НЕ БРОСАЕМ!

## Камышлинцы Zа наших

Илюся Гайнуллина.

В районе продолжается активный сбор гуманитарной помощи мобилизованным землякам. Очередные посылки с такой помощью вновь переданы нашим ребятам на передовую, в том числе отправлены на фронт первые три маскировочные сети, чтобы укрыть солдат и боевую технику. Вклад в общее дело вносят как взрослые, так и молодое поколение, активно приобщаясь к нужному ремеслу. «Понимаем, что это капля в море для фронта, но если мы вместе, объединившись, поддержим наших солдат, то победа будет за нами. Каждый из вас может помочь плести маскировочные сети. Даже 1-2 часа помощи очень важны! Присоединяйтесь, обучим!», - призывают земляков организаторы акции. Напоминаем, по всем вопросам звонить по телефону 89277647073.

Никто не остаётся в стороне. Истинный пример сочувствия и человечности тем, кто нуждается в поддержке, показывают многие неравнодушные жители района. В их числе глава КФХ Халит Шайхуллович Юсупов. Он передал 36 мешков муки и финансовую помощь семьям мобилизованных военнослужащих района.

Такая поддержка тыла, конечно же, вселяет солдатам веру в собственные силы, а самое главное в Победу. Мы благодарны всем, кто не остаётся в стороне!

МӘГАРИФ ӨЛКӘСЕНДӘ

# Мәскәү Ислам институтында иң яхшы белгечләрне әзерлиләр

ИРТӘН-ТӘМЛЕ БОТКА, УКУ ҺӘМ ТОРАК-БУШЛАЙ

**Мәскәүдәге Ислам институты турында шушы 3 сыйфатны әйтү җитәрме? Әле генә мәктәпне тәмамлаган баласын башкалага укырга җибәрүче ата-ана өчен алар үтә мөһим. Киләчәген теология белгечлеге белән бәйләргә теләгән абитуриентны МИИ тагын нәрсә белән кызыксындыра ала? Бу хакта югары уку йортының беренче проректоры Тимур Абдулхай улы Фәхретдинов белән сөйләштек.**



- Безнең институтның тарихы 1994 нче елдан башлана. Ул дини яңарыш, дини күтәрелеш чоры бит. Мөфтиебез шәех Равил Гайнетдин Ислам колледжын оештыра, үзе үк анда укыта да башлый. Колледж Җәмигъ мәчете территориясендә урнаша. Мәскәү Ислам институты-менә шул колледждан үсеп чыккан кадерле уку йортыбыз. 1999 нчы елдан бирле эшли. Хәзер без Үзәк федераль округта бердәнбер мөселман югары уку йорты. 2022 нче елда дәүләт аккредитациясен алдык һәм теология белгечлеге буенча дәүләт стандартындагы диплом бирәбез. Студентлар бакалавриат, магистратура, аспирантура программаларын үзләштерә ала.

**- Бу диплом МИИны тәмамлаган мөселманнарга дәүләт оешмаларында эшләү мөмкинлеген бирә диген сүзме?**

- Әйе, алар теологлар, дин белгечләре, тәрҗемәчеләр, мөгаллимнәр, шулай ук имамнар булып та эшли алачак. Ә иң мөһиме, алар безнең үзебезнең оешмалар өчен бик кирәкле белгечләр булачак. Беләсез, РФ мөселманнары Диния нәзарәте Россиядә иң эре дини оешма, илебезнең төрле өлкәләрендә урнашкан мәхәлләләрне берләштерә. Ә аларга дәүләт һәм төрле иҗтимагый оешмалар белән һәм шулай ук үзара хезмәттәшлек өчен белемле, законнарны белгән, эшне оештырырга өйрәнгән хезмәткәрләр кирәк. Алар дини яктан гына түгел, дөньяви яктан да әзерлекле булырга тиеш.

**- 2019-2020 нче еллар институт өчен авыр еллар булды дип беләм, ул чагында уку йортының лицензиясен саклау соравы да туды. Бу мәсьәләне ничек хәл итә алдыгыз?**

- Институт лицензиядән мәхрүм ителмәде. Ул вакытта Рособрнадзор (мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт) тикшеренүен уздык һәм нәтиҗәдә аларның күрсәтмәләре укыту һәм белгечләр әзерләү сыйфатыннан битәр, күбесенчә физик мөмкинлекләрдә чикләнгән кешеләр өчен шартлар тудыру, медицина кабинеты җиһазлары һ.б. шундый оештыру мәсьәләләренә кагылышлы булды. Аларның күпчелеге оператив рәвештә төзәтелде, кайберләрен исә бинада ремонт барганлыктан төзәтү мөмкин түгел иде. Бу турыдагы хисап федераль хезмәткә үз вакытында җибәрелде. Тикшерүчеләрне ул канәгатьләндермәде, алар судка мөрәҗәгать итте, әмма протоколлары дөрес тутырылмаганлыктан, суд 2 тапкыр эшне кире кайтарды. Шул вакытта безнең ректорыбыз Дамир Мөхетдинов булган лицензияне тапшыру, бинаны ремонтлау һәм аннары яңа лицензия алу турында карар кабул итте. Студентларны Россиядәге башка мөселман уку йортларына урнаштырырга туры килде. Бина төзекләндерелеп, яңадан ачылгач, аларның күбесе кире безгә кайтты. Аллаһы Тәгалә ул очракны безгә хәерлесе итеп биргән булып чыкты. Без Мәскәү Ислам институтын эчке һәм тышкы яктан яңадан кордык, дисәк тә, дөрес булыр. Аның ул чагындагы халәтен күрсәгез иде сез! Бу бина балалар бакчасы итеп төзелгән һәм шулай файдаланылган да. Безгә аны югары уку йортына җайлаштыру кирәк иде. Менә хәзер сез төп ишектән кердегез, ул балалар бакчасына охшаганмы, әллә институткамы?

**- Әйе, килешәм, институтның алгы залы бик җайлы, аңлаешлы һәм үзенә җәлеп итә торган килеп чыккан. Алдынгы укучылар стенды җәлеп итте, аларның күбесен беләм-Мәскәүдә һәм Россия төбәкләрендә танылган дин эшлеклеләре. Ә бинаның эчендә нәрсәләр бар, күрсәтә аласызмы?**

- Бик теләп күрсәтәм. Дамир хәзрәт белән утырып, бөтен ваклыгын уйлап, аякларыбыз белән йөреп чыгып төзедек. Мәсәлән, уң якта уку сыйныфлары урнашкан, алардан китапханәгә керәбез. Сүз уңаеннан, биредә китапларны кулга алып укып була, шулай ук шахмат-шашка да уйнап, ял итәргә дә була. Китапларның электрон каталогы да бар, әлбәттә. Сул якта төрле мәдәният бүлмәләре урнашкан. Аларда фарсы, гарәп, төрек һәм татар теле дәресләре укытыла. Спортка аерым игътибар бирдек: көрәш, тренажерлар, өстәл теннисы заллары аерым-аерым урнашкан. Күрәсез, һәр бүлектә санитар-гигиена бүлмәләре бар. Ә икенче каттагы сыйныф бүлмәләреннән соң, компьютерлар классы дәвам итә. Биредә интернетка чыгу, институтның электрон каталогына керү мөмкинлеге белән бергә, фәнни хезмәтләрне язу, аларны кәгазьгә чыгару һәм тегү мөмкинлеге дә бирелә. Күрше кибеттәге принтер бүлегенә чабарга кирәкми. Институтта барысы да бар һәм бушлай.

**- Бинаны физик мөмкинлекләрдә чикләнгән студентлар өчен дә җайлаштыра алдыгызмы соң?**

- Аларның ихтыяҗларын беренче чиратта кайгырттык. Урамнан башлап, бинага һәм эчтәге һәр бүлмәгә керү алар өчен җайлаштырылган. Әлегә андый студентларыбыз юк, әмма без аларны кабул итәргә әзер.

**-Тимур хаҗи, баласын берәр уку йортына кертергә теләгән ата-ана өчен уку сыйфаты белән беррәттән менә шушындый техник мөмкинлекләр, шиксез, бик мөһим. Шулай да аларны институтта укуның бәясе, керү имтиханнары һәм тулай торак мәсьәләсе бигрәк тә кызыксындырадыр дип уйлыйм. МИИ да уку елына ничә сум тора?**





- Мәскәү Ислам институтында белем алу түләүле дә һәм шул вакытта бушлай да була ала. Ничекме? Хәзер аңлатам. Беренчедән, 1 курс бакалавриат программасына керү имтиханнары болай: рус теле, җәмгыять белеме һәм дин нигезләре. Аларның беренче икесе БДИ баллары нигезендә, ә дини имтихан әңгамә рәвешендә кабул ителә. Беренче елны уку 70000 сум. Әмма ул инде беренче семестрдан 90%ка кадәр киметелергә мөмкин. Институт студентының укырга сәләте, омтылышы һәм уңышлары бар икән, ул гариза язып, түләү бәясен киметүне сорарга хаклы. МИИ советы җыела да, аның мөрәҗәгатен карый. Әйе, ул сәләтле, теләп укый һәм киләчәктә аның динебезгә, илебезгә хезмәт итәчәгенә өмет бар икән, түләү бәясе төшерелә. Безнең андый хәл булды, 1 курс студентының уку өчен түләве 70 меңнән 7 меңгә калды. Ә тулай торакка килгәндә, әлегә без көндезге бүлек студентлары өчен фатирга кереп тору мөмкинлеген булдырдык, аренда өчен институт түли. Киләчәктә, институт җирендә тулай торак бинасын төзергә ниятлибез. Аннары тагын бер мөһим нәрсәне әйтеп узасым килә: безнең студентлар көнгә 3 тапкыр бушлай туклана. Мәсәлән, аларның иртән институтка килгәч, иң беренче эше-иртәнге ашны ашау: ботка, ипи белән май, сыр, җимешле чәй һәм компот. Аннары сәгать 9 да дәрес башлана, ике пардан соң көндезге аш. Яңа намаз бүлмәсендә барыбыз бер җәмәгать булып, өйлә намазын укыйбыз. Аннары студентлар кабат дәресләргә тарала. Ике пардан соң өстәмә дәресләр өчен вакыт бирелгән, аннан соң- кичке аш. Студентлар көне буена институтта булсын, тамаклары тук булсын һәм укырга бернәрсә дә комачауламасын өчен шулай бар шартларны да тудырырга тырышабыз.

**- Алар үзләрен эти-әнисе йортында яшәгәндәй хис итәләрдер, дип уйлыйм. Ә укудан тыш студентлар тагын нәрсә белән шөгыльләнә?**

- МИИда студентларның ялын оештыру да уйланылган. Шимбә көннәрендә мөгаллимнәр аларны музейларга, күргәзмәләргә алып бара. Беләсез, Мәскәү каласында карар нәрсә бихисап. Күптән түгел төрле конфессияләр арасында оештырылган шахмат турнирында булдылар, алар башка фикерле кешеләрне күрәләр. Шулай студентның дөньяга карашы киңәя. Замана дин эшлеклесе өчен бу бик мөһим һәм кирәкле сыйфат. Мәскәү Ислам институты имамнар әзерләү максатын гына куймый. Безнең институтка укырга кереп, алар бераз башка киләчәкне күрергә тиеш. МИИны тәмалап, алга таба магистратура яки аспирантураны сайлап, алар фәнни эшләрен Санкт-Петербург, Мәскәү шәһәрләрендәге фәнни үзәкләрдә яклаячакларын белергә тиеш. Мондый гыйлем баскычы башка дәрәҗә бирә. Мөселманнарның урыны мәчет белән генә чикләнергә тиеш түгел бит. Мәхәлләләргә төрле дәрәҗәдә эш алып барырдай, һәркем белән уртак тел таба алырдай, динебезнең асылын күрсәтердәй белгечләр кирәк.

**- Тимур хаҗи, шундый киң кырлы дин эшлеклесе булырга әзер булучылар күпме, институтка укырга керүчеләр арасында конкурс нинди?**

- Кызганыч, сезнең сорауга җавапны, шулай кызганыч дип башларга мәҗбүрмен. Мөселман югары уку йортларына укырга керергә атлыгып торучылар юк, озын чират күрмибез. Бу бөтен Россия ВУЗлары буйлап күзәтелә торган хәл. Моның сәбәпләре берничә. Беренчедән, теология яңа белгечлек, аның нинди фән икәнлеген җәмгыять әле белеп бетерми. Әмма теологиянең киләчәге бар, чөнки Аллаһ белән адәм баласы арасындагы мөгаләмә бар, җан бар, үзеңне һәм башкаларны аңламыйча тулы канлы тормыш алып барып булмый. Икенчедән, абитуриентлар динне белми, аны һөнәр буларак күрми.

⇨

МӘГАРИФ ӨЛКӘСЕНДӘ

# Мәскәү Ислам институтында иң яхшы белгечләрне әзерлиләр



МИИ РЕКТОРЫ, ТЕОЛОГИЯ ФӘННӘРЕ ДОКТОРЫ **ДАМИР МӨХЕТДИНОВ:**

**- Россиянең яңа тарихында беренче мәртәбә "Аллаһ" сүзе илнең Конституциясендә язылды. Димәк ки, гражданнарының Аллаһка ышануы дәүләт өчен бик әһәмиятле. Россиядә инде 2007 нче елдан бирле теология фәнен үстерү юнәлешендә эзлекле эш алып барыла. Хәзерге вакытта теология фән буларак кабул ителде һәм аның буенча диссертацияләр языла, яклана. Аллаһка ышанган шәхеснең җәмгыять тормышындагы ролен дәүләт аңлый һәм рухи-әхлакый кыйммәтләрне саклауда дин белгечләренең урынын югары бәяли дигән сүз. Ә дин белгечләре алар-теологлар. Дәүләт теологларга ышана һәм андый белгечләрне үзебездә әзерләү яклы. Шуңа күрә теология белгечлеген алган яшьләрнең киләчәге бар, аларны әзерләүдә дәүләт үзе ярдәм итә. Моннан чыгып, акыллы, кешеләр белән аралаша белгән һәм оста белгечләргә киң перспектива ачыла дигән сүз. Мәскәү Ислам институтын тәмамлаган шәхесләр мисалында күрүебезчә, алар ил үсешендә актив катнаша, җәмгыятьтә лаеклы урыннарын тапкан һәм үз-үзләре, җәмгыятьнең башка әгъзалары белән килешеп яшиләр.**

Өченчедән, безнең мәхәлләләр никадәр генә имам кирәк, мөгаллим кирәк, дип "еласа" да, үзләре өчен кандидат сайлап, аларны укырга җибәрми. Монысы нык аптырашта калдыра. Әмма Мәскәү институты куелган максатыннан тайпылырга җыенмый. Без җәмгыять өчен киң кырлы белгечләр әзерләргә телибез, без моңа әзер.

**- Сез санап узган сәбәпләрне генә үзгәртәсе кала. Бу юнәлештә МИИның планнары нинди?**

- Тагын бер кат кызганыч, дияргә кала: институт бүген үзенә студентлар эзләргә мәҗбүр. Гәрчә, югары уку йортының вазыйфасы-укыту сыйфатын кайгырту. Яшьләр динне белмәгәч, дини белгечлекнең киләчәген күрмәгәч, төбәк мәхәлләләре һич югында, бер кешене укырга җибәрә алмагач, без аларны үзебезгә әзерләргә кирәк дигән ният белән яна башладык. Бу тормышка ашырылмаган әле, әмма фикеребез шундый: 10-11 сыйныф укучылары өчен төбәкләрдә һәр атнаны Ислам дине нигезләре дәресләрен оештыру. Билге һәм грамота кәгазе өчен түгел, ә күзаллау һәм төшену өчен. Ислам институты белән таныштырып, дин нигезләрен өйрәтеп, алардан үзебез өчен абитуриентлар ясау. Калган белемнәрен институтта биреп бетерә алабыз. Мәсәлән, безнең укыту программасында төп өлештән тыш, факультатив та бик көчле каралган. Студент гарәп теле яки тәҗвид фәненнән, яки шул ук рус теленнән, мәсьәлән, башкалардан калышуын сизсә, ул мөгаллим белән аерым шөгыльләнә алачак. Башка фәннәрдән дә андый мөмкинлек каралган. Бу бушлай һәм укыту расписаниесе буенча каралган. Без яшь кешене кабул итеп, ул акча гына түләсен, дигән фикердә тормыйбыз. Безнең максат-укыту һәм шәхес тәрбияләү, аңа һәр яклап булышу.

**- Институтта ачык ишекләр көне кайчан булачак?**

- Бездә ул һәр көнне була ала. Ата-ананың һәм абитуриентның Мәскәү Ислам институты белән танышасы килсә, киләсе көннәрен генә хәбәр итәргә кирәк. Мин аларны үзем каршы алам, күрсәтәм һәм аңлатам. Рәхим итсеннәр.

**- Тимур Хаҗи, эчтәлекле, тулы әңгәмәгез өчен зур рәхмәт! Игелекле, изге хезмәтегездә зур уңышлар, Сезгә!**

БЕЗГӘ ЯЗАЛАР



# САГЫШЛЫ ДА, ШАТЛЫКЛЫ ДА БӘЙРӘМ

*Кояш балкый бер битендә,*
*Бер битендә моңсу ай сыман.*
*Бер күзеңнән шатлык*
*нуры сибелә,*
*Бер күзеңнән һаман*
*яшь тама...*

Мондый сагышлы да, шатлыклы да бәйрәм башка юк кебек. Бәйрәмнәрнең дә бәйрәме булган Җиңү көне гөрли бүген. Чыннан да, 78 ел элек ата-бабаларыбызның аяусыз батырлыгы, тырышлыгы, илгә чиксез мәхәббәте белән яуланган җиңү булмаса, башка бәйрәмнәр узар иде микән?!

Иске Усман авылында һавада, урамнарда иртәдән үк бәйрәм тантанасы хөкем сөрә: дәртле җыр тавышы, учак исе, язгы табигый исләр, җанлы матурлык дөньяны каплый. Муса Җәлилнең "Бүреләр" шигырен үзәк өзгеч итеп укыды, Мәгърифә апа Гыйльфанова "Солдатлар" җырын башлауга, барча халык күтәрелеп алды, Адилә Юнысова "Каеннар шаулый" җыры белән күңелләргә үтеп керде. "Сандугач" балалар бакчасында тәрбияләнүче балалар да үзләренең матур шигырьләрен, җырларын бүләк иттеләр. Тәрбиячеләре Гөлия һәм Гүзәл Кәримоваларга рәхмәтләрнең чиксезе. Авыл советы депутаты Гомәр ага Мөниров та бәйрәм белән котлап, матур теләкләрен җиткерде. Авыл халкы исеменнән рәхмәт сүзләрен Фидания апа Нуретдинова белдерде. Бар чыгышларда да бер теләк, бер хыял:бүгенгесе



Бәйрәм оештыручылар кунак каршыларга әзер: чәчәкләр куелган, утыргычлар тезелгән. Менә кунаклар да күренә. Аяныч, сирәгәйделәр шул алар! Инде сугышта катнашкан агайларыбыз, аларны сагынып көткән, авылында көне-төне хезмәт куйган тыл батырларыбыз да дөнья белән хушлашты. Балалар, яңа туып калган, балалыктан чыкмаган сабыйлар- шул вакытта сугыш авырлыгын татыган авылдашларыбыз-бәйрәмнең мөхтәрәм кунаклары.

Бәйрәмне алып баручылар шигъри юллар белән тантананы ачып җибәрделәр. Иң беренче, сугыш корбаннарын искә алып, Коръән укылды. Аннан котлау өчен сүз авыл идарә башлыгы Фәнил Кәримовка бирелде. Фәнил Рафаэль улы кунакларны, авыл халкын бәйрәм белән котлап, иң изге теләкләрен җиткерде. Күз яшьле, шатлыклы бәйрәм алып баручыларның тирән мәгънәле шигырьләре белән үрелеп барды. Пенсионер-укытучы Тәслимә апа Борһанова көнне сугышта булган барлык ир-егетләребез Җиңү яулап, исән-имин кайтсыннар иде. Өйдә бит аларны балалары, хатыннары, әти-әниләре, әбибабалары, сөйгән ярлары түземсезлек белән көтәләр, борчылалар. Тизрәк бетсен бу сугыш. Тагын Җиңү көне булсын, күкләребез аяз, илебез тыныч булсын!

Бәйрәмнең бөтен шартын китердек: бер минут тынлык та булды, һәйкәлебезгә чәчәкләр дә куйдык, шарлар да очырдык, хуш исләр чыгарып солдат боткасы да пешердек, өстәлләр дә әзерләдек. Тәмтомнар тулы өстәлләр артында хуш исле чәй белән дә сыйландык.

Ә кичен һәйкәл каршында шәмнәр яндырып, яу кырында ятып калган, исән-сау кайтып та бүгенгесе көнне бакыйлыкка күчкән авылдашларыбызны искә алдык.

**Г.Д.Вәлиуллина - китапханәче,**
**Р.Х.Надыршина- клуб мөдире.**
**Иске Усман авылы.**

ИСЛАМ НУРЫ

# Сынаулар

Аллаһ Тәгалә кешеләрне төрле сәбәпләр аркасында сыный. Галимнәр кешегә килгән сынауларны өч сәбәп белән аңлаталар.

Әт-тәнкийә-кемнең кем икәнен ачыклау өчен.

Чыннан да, Аллаһка ышанамы һәм Аңа гыйбадәт кыламы икәнлеген ачыклау өчен Аллаһ Тәгалә адәм баласына төрле сынаулар җибәрә. Шул рәвешле Аллаһ Тәгалә аның хакыйкатьтә кем булуын үзенә һәм башка кешеләргә күрсәтә. Кайбер кешеләр рәхәт вакытта үзен дини яки Аллаһка ышанучы, намаз укучы, мәчеткә йөрүче кеше итеп күрсәтә, ә сынау вакытында боларның бөтенесен дә ташлый. Бу хәл әлеге кешенең ихлассызлыгын күрсәтә. Аллаһ Тәгалә шулай ди: "Без сезне арагызда дин юлында тырышучыларны һәм сабыр итүчеләрне белү өчен сыныйбыз". (Мөхәммәд-31).

Әт-Тәрбия-тәрбияләү өчен. Аллаһ Тәгалә кешене туры юлга бастыру өчен төрле сынаулар җибәрергә мөмкин. Сынауларга хәтле кеше Аллаһ Тәгаләгә гыйбадәт кылмыйча, гөнаһларга чумып яши, ә бәла-казалар күрә башлагач Аллаһ Тәгаләгә кайта. Аллаһ Тәгалә шулай ди: "Без аларга зур газаптан түбәнрәк газапны чыннан да татытачакбыз. Бәлки алар туры юлга кайтырлар". ("Сәҗдә" с.21а).

Ибн Габбас (р.г.) әлеге аятьне аңлатып шулай ди: "Түбәнрәк газап-ул дөньядагы бәла-казалар, авырулар һәм афәтләр. Аллаһ Тәгалә кешеләргә бу бәла-казаларны Үзенә кайтсыннар өчен җибәрә". Әгәр дә Аллаһ Тәгалә Үзе яраткан кешенең әҗер-савабын, дөньядагы һәм җәннәттәге дәрәҗәсен күтәрергә теләсә, Ул аңа төрле сынаулар җибәрә. Мөхәммәд (с.г.в.) шулай ди: "Әҗер-савапның зурлыгы сынауның зурлыгына карап. Әгәр дә Аллаһ Тәгалә бер төркем кешеләрне яратса, аларны сыный. Кем дә кем моңа риза булса, Аллаһ Тәгалә алардан риза була, ә кем дә кем ачуланса, аңа Аллаһ ачулана". (Тирмизи, Ибн Мәҗәһ). Әгәр дә 40 көн эчендә берәр сынау килмәсә, Гомәр ибн Хаттаб: "Әллә Аллаһ Тәгалә миңа ачуланды микән?"- дип әйтә торган булган. Кади Әш-Шурайһ исемле кеше шулай дип әйткән: "Әгәр миңа сынау килсә, Аллаһны 4 нәрсәне искә төшереп мактыйм: беренчесе, бу сынау элеккесеннән зуррак булмаганы өчен, икенчесе, әлеге сынауны үткәреп җибәрергә сабырлык биргәне өчен, өченчесе, сынау килгәч, "Иннә Лилләһи вә Иннә иләйһи раҗигун". (Дөреслектә, без Аллаһныкы һәм без Аңа кайтачакбыз) дип әйтеп, савап язганы өчен, һәм дүртенчесе, бу сынау Ислам дине белән бәйле булмаганы өчен".

(Дәвамы бар).

Материалларны басмага Рәйсә Төхбәтшина әзерләде.

## КОТЛЫЙБЫЗ!

**Иске Ярмәк авылы**
**Сәһия Атлас кызы**
**Фәтхетдиновага-60 яшь**

Кадерле кызым, тормыш иптәшем, газиз әниебез! Сине юбилееӊ белән саф күӊелдән тәбриклибез.

*Елмайсаӊ йөзеӊнән аӊлыйбыз,*
*Әниебезнеӊ теләген.*
*Дөнья киӊлегенә тиӊлибез,*
*Әнкәебезнеӊ йөрәген.*
*Әнкәй сиӊа бүләк итәбез,*
*Бөтен дөнья гөлләрен.*
*Юллар кебек озын булсын,*
*Әнкәебез гомерләреӊ.*
*Ай нурыннан да нурлырак,*
*Әнкәй синеӊ йөзләреӊ.*
*Моӊлы көйдәй күӊлебездә,*
*Әнкәебез синеӊ сүзләреӊ.*

Әниеӊ, тормыш иптәшеӊ, балаларыӊ.

**ПРОФЛИСТ некондиция И IС. ДЕШЕВО. СТОЛБЫ. ПРОФТРУБА.**
ТЕЛ: 8-927-716-65-55.
РЕКЛАМА

**БУРЕНИЕ ПОД ВОДУ.**
ТЕЛ: 8-927-748-20-05.
РЕКЛАМА

**НАТЯЖНЫЕ ПОТОЛКИ. АКЦИЯ 180Р/КВ.М.**
ТЕЛ: 8-927-797-05-88 (РИФАТ).
РЕКЛАМА

**УТЕПЛЕНИЕ ЖИДКОЙ ПЕНОЙ ППУ: НАПЫЛЕНИЕ, ЗАПОЛНЕНИЕ ПУСТОТ.**
Тел: 8-927-763-35-63.
РЕКЛАМА

Выпускники 2019 и 2021 годов Староермаковской средней школы и их родители выражают глубокое соболезнование классному руководителю Гатиной Фании Геннадьевне по поводу скоропостижной смерти сына
**ГАТИНА**
**Алмаза Филатовича.**

Выпускники 1976 года Староермакоской средней школы выражают глубокое соболезнование однокласснице Гатиной Фании Геннадьевне по поводу скоропостижной смерти сына
**ГАТИНА**
**Алмаза Филатовича.**

**ПРОДАЕТСЯ:**
- крапиворезка. Тел: 8-927-734-06-46.
***
- бычки от одного до трех месяцев. Тел: 8-927-831-16-26.

**ЗАКУПАЮ**
говядину: коров, быков, телок.
Тел. 8-927-753-45-07.

**Извещение о необходимости согласования проекта межевания земельного участка образуемого путем выдела из земельного участка с кадастровым номером 63:20:0000000:40**

Кадастровым инженером Рахматуллиным Расимом Шавкатовичем, 446910, Самарская область, Шенталинский район, ст. Шентала, ул. Советская, д.10, IP_Rasim-i-Nadegda @mail.ru, тел.89376526670, квалификационный аттестат № 63-11-310, выполнен проект межевания земельного участка, образуемого путем выдела из земельного участка с кадастровым номером 63:20:0000000:40, расположенного по адресу: Самарская область, Камышлинский район, земли бывшего колхоза «Родина».

Заказчиком работ является Хабибуллин Анвар Ансарович, адрес: 446977, Самарская область, Камышлинский район, с. Новое Ермаково, ул. Центральная, д.20, тел. 8-937-792-75-54.

В течение 30 дней с момента опубликования настоящего извещения собственники земельного участка с кадастровым номером 63:20:0000000:40 могут ознакомиться с проектом межевания земельного участка по адресу:446910, Самарская область, Шенталинский район, ст. Шентала, ул. Советская, д.10, кадастровый инженер Рахматуллин Расим Шавкатович.

Обоснованные возражения относительно размера и местоположения границ земельного участка, выделяемого в счет земельных долей принимаются также в течение 30 дней с момента опубликования настоящего извещения по адресу: 446910, Самарская область, Шенталинский район, ст. Шентала, ул. Советская, д.10, кадастровый инженер Рахматуллин Расим Шавкатович.

**Комитет сельского хозяйства и продовольствия с 15 мая 2023 года начал прием документов для возмещения затрат на содержание маточного поголовья КРС в ЛПХ(коров).**

Список документов:

Заявка, справка-расчет, выписка из похозяйственной книги, копии документов на затраты:

- от ЛПХ: договор купли-продажи, акт приема-передачи товара, акт приема-передачи денежных средств);
- от КФХ и других юридических лиц: договор купли-продажи, товарно-транспортная накладная, чекоб оплате или квитанцию к приходному ордеру).

А также в расчет принимаются другие затраты на содержание коров за 2022-2023 год.

По возникающим вопросам обращаться по тел. 3-34-37 Файзуллин Д.Г.

**КРОВЛЯ** региональная сеть
15 ЛЕТ С ВАМИ! В ЧЕСТЬ ЮБИЛЕЯ – ДОСТАВКА БЕСПЛАТНО!
РЕКЛАМА
**САЙДИНГ, ПРОФНАСТИЛ**
ЗАМЕР, РАСЧЁТЫ, КОНСУЛЬТАЦИЯ **БЕСПЛАТНО**
8 (937) 074-36-36, 8 (927) 200-24-99

**ТЕПЛИЦЫ**
**БЕСЕДКИ**
**КАЧЕЛИ**
с доставкой и установкой!
8-927-759-50-55
8-927-294-05-34
ОПТОВЫЕ ЦЕНЫ. СКИДКИ ПЕНСИОНЕРАМ.
РЕКЛАМА

**ИЗ ПОЧТЫ РЕДАКЦИИ**

# Моя семья - моя Отчизна

**15 мая отметили Международный день семьи – праздник, посвящённый главному источнику любви, уважения, солидарности и привязанности. Именно в этот день можно лишний раз сказать родным и близким о том, как сильно мы их любим.**

В рамках празднования дня семьи в Новоермаковском сельском клубе и библиотеке провели конкурс рисунков на асфальте «За мирное небо». Все очень старались! Ребята оставили частичку доброты своих сердец в живописи на асфальте!



В этот же день в рамках празднования дня семьи в сельском клубе совместно с библиотекой провели семейную спортивную эстафету «Быстрее. Выше. Сильнее». Программа соревнований была насыщенной. Командам были предложены очень непростые конкурсы в беге, прыжках и эстафеты с мячом и обручем, в которых нужно было проявить меткость и сообразительность, спортивные, умственные способности и навыки. Все этапы этого увлекательного соревнования проходили в напряженной борьбе, было интересно наблюдать за стремлением команд к победе, «болеть» и поддерживать каждого участника. Все участники мероприятия получили заряд положительных эмоций и море позитива.

**А.Г. Хамидуллина, завклубом,**
**А.М. Заляева, библиотекарь.**



# Урок на тему «Пожарная безопасность»

5 мая инструктор противопожарной профилактики Лилия Халимова провела открытый урок для учеников школы с.Камышла по теме «Пожарная безопасность». Учащиеся учебного заведения с интересом слушали о роли огня в жизни человека, что делать и как действовать в том случае, если случится пожар, а также побеседовали об основных мерах пожарной безопасности, о правилах эвакуации при спасении людей из горящего помещения и посмотрели видеоролики про пожарную безопасность в быту.

Пожарная часть №120 Камышлинского района призывает взрослых и детей соблюдать правила пожарной безопасности. Ученикам нужно, как можно чаще напоминать и рассказывать о правилах пожарной безопасности, о том, что «спички детям - не игрушки». Нужно не только предостеречь детей от пожаров, но и научить их действовать в таких ситуациях, если случился пожар. Ведь частенько дети даже не знают о том, что делать во время пожара. Если же рядом есть взрослые, сразу звать их на помощь. Если же пожар только начался, то его легко потушить водой, или, накрыв толстым одеялом, также можно забросать землей из цветочного горшка. Если нет возможности справиться с огнем, то нужно незамедлительно покинуть помещение, защитить нос и рот влажной тканью.

**Л.Халимова, инструктор противопожарной профилактики ПСЧ №120**

**Адрес редакции и издателя:**
446970 Самарская область, Камышлинский район с. Камышла, ул. Победы, 37 А
электронная почта: miznur@mail.ru
наш сайт: www.kamizvestiya.ru
**Телефоны:**
Руководитель: 3-31-47,
ответственный секретарь, корреспонденты, верстка, рекламный отдел: 3-30-61.

12+

Руководитель центра и главный редактор Р.Т.БАДРЕТДИНОВ.
Газета выходит по вторникам и пятницам.
Объем - 1 печатный лист.
Отпечатана в МУП "Сергиевское полиграфическое предприятие". 446540 Самарская область, с.Сергиевск, ул. Ленина, 14.
Номер подписан в печать 18.05.2023 г.
Фактически в 12.00. По графику в 12.00
Заказ № 453

Редакция может не разделять точку зрения автора.
Присланные материалы могут подвергаться редакционной правке. Редакция не несет ответственности за содержание рекламных материалов, их политическую направленность и правдивость. Письма, рукописи, иллюстрации не рецензируются и не возвращаются.
Подписной индекс П6384
Цена свободная. Тираж - 1200 экз.

**Учредители**: Администрация муниципального района Камышлинский Самарской области.
Газета "Камышлинские известия" зарегистрирована в Управлении Федеральной службы по надзору в сфере связи, информационных технологий и массовых коммуникаций по Самарской области. Регистрационный номер ПИ № ТУ 63-00744 от 02 декабря 2014 года.
Ответственный секретарь: И.ГАЙНУЛЛИНА
Верстка: Р.ПОЛУКАРОВ.